СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 сентябрь 2018 ел г.Мензелинск № 10

# МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҮЗ ВАЗИФАЛАРЫН ДАИМИ НИГЕЗДӘ БАШКАРУЧЫ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАНЫНА САЙЛАНГАН ВАЗИФАИ ЗАТЛАРНЫ, МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЕ БУЛМАГАН ВАЗИФАЛАРНЫ БАШКАРУЧЫ ЗАТЛАРНЫ КОМАНДИРОВКАГА ҖИБӘРҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА

Татарстан Респубикасының 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында”гы №18-ЗРТ Законының 21 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Уставы нигезендә

МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының үз вазифаларын даими нигездә башкаручы җирле үзидарә органына сайланган вазифаи затларны, муниципаль хезмәткәрләрне һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәре булмаган вазифаларны башкаручы затларны командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында”гы Положениене расларга (Кушымта №1).
2. 20.06.2011 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының үз вазифаларын даими нигездә башкаручы җирле үзидарә органына сайланган вазифаи затларны, муниципаль хезмәткәрләрне һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәре булмаган вазифаларны башкаручы затларны командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында”гы №4 Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советы карары көчен югалткан дип санарга.
3. Гамәлдәге карарны “Интернет” челтәрендә Минзәлә район хакимиятенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Гамәлдәге карарны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район бюджеты чаралары хисабыннан башкарырга.

Совет рәисе А.Ф.Салахов

Кушымта №1
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Советы
Карарына
Дата14.09.2018 ел. N 10

**МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҮЗ ВАЗИФАЛАРЫН ДАИМИ НИГЕЗДӘ БАШКАРУЧЫ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАНЫНА САЙЛАНГАН ВАЗИФАИ ЗАТЛАРНЫ, МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЕ БУЛМАГАН ВАЗИФАЛАРНЫ БАШКАРУЧЫ ЗАТЛАРНЫ КОМАНДИРОВКАГА ҖИБӘРҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА ПОЛОЖЕНИЕ**

1. ТР Минзәлә муниципаль районының үз вазифаларын даими нигездә башкаручы җирле үзидарә органына сайланган вазифаи затлар, ТР Минзәлә муниципаль район Советының, ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләргә кагылмаган вазифаларны башкаручылар (алга таба – эшләүчеләр)ТР Минзәлә муниципаль районы Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе карары белән хезмәт бурычларын билгеле бер срокта башкару өчен хезмәт командировкаларына, шул исәптән, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе территорияләренә җибәрелгән кебек, чит дәүләт территорияләренә дә һөнәри әзерлек, квалификацияне күтәрү максатларында (муниципаль хезмәтне башкаруның даими урыныннан, эш урыныннан тыш) җибәреләләр.
2. Хезмәт командировкаларына штатта торган хезмәткәрләр, шулай ук ТР Минзәлә муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органында гражданлык-хокукый килешүе буенча эшләүчеләр (алга таба – эшләүчеләр) җибәрелә.
3. Хезмәт бурычының күләмен, катлаулыгын һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт органнарының чакыру хатлары нигезендә, хезмәт командировкаларының срогы ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.
4. Поезд, самолет, автобус һәм башка транспорт чарасының муниципаль хезмәттә эшләүчеләрнең даими хезмәт, эш урыныннан китүе хезмәт командировкасына китү көне дип санала, ә күрсәтелгән транспорт чарасының эшләүче даими муниципаль хезмәт узучы эш урынына кайткан көне хезмәт командировкасыннан кайткан көне дип санала.

Транспорт чарасы белән 24 сәгатьне кертеп хезмәт командировкасына киткән көн агымдагы тәүлек булып санала, ә 00 сәгатьтән соң һәм аннан да соңрак – алдагы тәүлекләр дип санала.

Әгәр тимер юл яисә автостанция, пристань, аэропорт торак пункттан читтә урнашкан булса, станциягә, пристаньга, аэропортка кадәр барасы юлны узуга кирәк булган вакыт исәпкә алына. Эшләүченең муниципаль хезмәтне даими узу урынына, эш урынына кайткан көне дә шул ук юл белән билгеләнә.

Эшләүченең хезмәт командировкасына киткән һәм хезмәт командировкасыннан кайткан көнне хезмәткә, эш урынына килү мәсьәләсе эш бирүченең вәкиле яисә аның вәкаләтле заты билгеләгән тәртиптә хәл ителә.

5. Эшләүченең хезмәт командировкасына җибәрелүе хезмәтне исәпкә алу һәм аңа түләү буенча беренчел учет документациясенең билгеләнгән унификацияләнгән формалары нигезендә, беренчел учет документлары белән рәсмиләштерелә.
6. ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы нигезендә, муниципаль органның җаваплы заты хезмәткәргә командировкаланган урынга барып җиткән (билгеләнгән пунктка килеп җитү һәм аннан китү датасы), командировкада булган срокны раслаучы командировка таныклыгын рәмиләштерә.
7. Командировка таныклыгы бер экземплярда рәсмиләштерелә һәм вәкиллекле зат тарафыннан имзалана. Командировка таныклыгы эшләүчегә тапшырыла һәм хезмәт командировкасы срогы төгәлләнгәнче аның үзендә саклана.

Командировка урынында факт буенча булган вакыт командировка таныклыгында билгеләнә һәм вәкаләтле вәкиллекле зат белән имзаланган һәм әлеге имзаны раслау өчен оешмада кулланыла торган мөһер белән командировка урынына килгән һәм аннан киткән дата турында билге буенча раслана.

Әгәр дә хезмәткәр төрле торак пунктларда урнашкан берничә оешмага җибәрелә икән, командировка таныклыгында аның килү һәм китү вакыты һәрбер оешмада билгеләнә.

8. Муниципаль органнар хезмәт командировкаларына киткән һәм килгән эшләүчеләрне махсус журналда билгелиләр.
9. Хезмәткәрне хезмәт командировкасына җибәргәндә, аңа вазифасы һәм уртача хезмәт хакы саклану гарантияләнә, шулай ук түбәндәгеләр саклана:

а) командировка урынына барган һәм муниципаль хезмәт яки эш урынына кире кайту өчен тотылган чыгымнар;

б) хезмәткәр төрле торак пунктларда урнашкан берничә дәүләт органына командировкага җибәрелгән икән, бер пункттан икенчесенә күчү өчен тотылган чыгымнар;

в) торак бинаны наемга алу буенча чыгымнар;

г) даими яшәү урыныннан читтә яшәү белән бәйле  өстәмә чыгымнар (“суточный” тәүләүләр)

д) командировка урынында вазифаи затларны башкару белән бәйле һәм ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципальрайон башкарма комитеты җитәкчесе буенча эшләүчеләргә кайтарып бирелә торган башка чыгымнар.

10. Эшләүче чит дәүләт территориясенә хезмәт командировкасына киткән очракта, аңа өстәмә рәвештә түбәндәге чыгымнар кайтарыла:

а) чит ил паспортын, визаны һәм башка чит илгә чыгу документларын рәсмиләштерүгә тотылган чыгымнар;

б) мәҗбүри консул һәм аэродром җыемнары;

в) чит илгә керү хокукы яисә автомобиль транспорты транзиты өчен җыемнар;

г) мәҗбүри пенсия иминиятен рәсмиләштерү өчен чыгымнар;

д) башка мәҗбүри түләүләр һәм җыемнар.

11. Командировкага җибәрелгән эшләүче вакытлыча эшкә яраксыз булган очракта, торак бина наемы буенча чыгымнар кире кайтарыла (командировкага килгән хезмәткәр стационар дәвалануда булмаган очракта) һәм сәламәтлеге начар булу сәбәпле ул үзенә йөкләнгән вазифаны башкара алмаган яисә даими эш урынына кайта алмаган чор өчен тәүлеклек акчалар (суточные) түләнә.

Вакытлыча эшкә яраксыз чор өчен эшләүчегә Россия Федерациясе законнары нигезендә вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособие түләнә.

14. Хезмәткәр командировкага җибәрелгән орган яки оешма аны хезмәт урыны, кирәкле материал һәм җиһазлар белән, шулай ук вазифаи бурычларны үтәү өчен хезмәткәргә кирәкле булган барлык төр элемтә, транспорт чаралары белән тәэмин итәләр.

15. Даими тору урыныннан читтә яшәү белән бәйле өстәмә чыгымнар хезмәткәргә ял һәм бәйрәм көннәрен, шулай ук юлда булган вакытны, шул исәптән мәҗбүри туктаган вакытны да кертеп, хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен Россия Федерациясе чикләрендә (Мәскәү һәм Санкт-Петербугр шәһәрләреннән тыш) командировка өчен – 200 сум, ә Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренә командировка өчен 300 сум күләмендә түләнә.

16. Эшләүче транспорт хәрәкәте шартлары һәм башкара торган вазифа төре буенча көн саен даими яшәү урынына кайту мөмкинлеге булган урынга командровкага җибәрелгән очракта, тәүлеклек акчалар түләнми.

Әгәр командировкага җибәрелгән эшләүче эш көне тәмамлангач эш бирүче вәкиле яисә аның вәкиллекле заты белән килешенү буенча командировка урынында кала икән, торак бинага наем турында документлар булган очракта, чыгымнар федераль бюджеттан финанслана торган оешмалар өчен Россия Федерациясе билгеләгән күләмдә кайтарыла.

14. Торак бинаны броньлау һәм наемга алу буенча чыгымнар (бушлай торак бина бирелгән очраклардан тыш) командировкага җибәрелгән эшләүчеләргә тиешле документлар белән расланган чынлыкта тотылган чыгымнар буенча түбәндәге нормаларга нигезләнеп кайтарыла:

а) муниципаль хезмәтнең “җитәкче” югары вазифасын башкаручы муниципаль хезмәткәрләргә – бер урынлы торак өчен бәядән кыйммәт булырга тиеш түгел (бер-, ике бүлмәле номерларга);

б) калган эшләүчеләргә – бер бүлмәле ( ике булмәле) номер өчен бәядән артык булмаган күләмдә.

15. Торак пунктта кунакханә булмаган очракта, эшләүчегә аерым торак бинаны наемга алган яисә яшәү урыныннан командировкаланган урынга кадәр һәм икенче якка кайту өчен гарантияләнгән транспорт чарасы белән якындагы торак пунктта торак бина өчен чыгымнар кире кайтарыла.

Раслаучы документлар булмаган очракта (кунакханәдә урын бирелмәгән очракта), торак бинаны наемга алган өчен чыгымнар хезмәт командировкасында булган һәр тәүлек өчен билгеләнгән норманың 30 проценты күләмендә кире кайтарыла.

Эшләүче командировкага барган юлда мәҗбүри тоткарлана икән, торак бинаны наемга алу буенча тиешле документлар белән расланган, гамәлдәге тәртип һәм шартларда билгеләнгәнчә, чыгымнар кире кайтарыла.

16. Командировкага җибәрелгән эшләүчеләргә торак бинасын наемга алу буенча хезмәтләр Россия Федерациясе хөкүмәте белән расланган, Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

17.Эшләүченең командировкаланган урынга бару һәм даими эш урынына кире кайту буенча чыгымнары (транспорттагы пассажирларның мәҗбүри пенсия иминиятенә иминият взносын, юлда йөрү документларын рәсмиләштерү буенча хезмәтләргә түләү, поездда урын-җир әйберләре бирүне кертеп), шулай ук эшләүче төрле торак пунктларында урнашкан берничә оешмага җибәрелгән булса, бер торак пунктыннан икенчесенә һава, тимер юл, су һәм автомобиль транспорты белән бару өчен расланган юл йөрү документлары өчен чынлыкта тотылган чыгымнар буенча түләнә.

18. Юл йөрү документлары булмаган очракта түләүләр башкарылмый. ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән, нигезләмә булган очракта, командировкаланган урынга һәм даими эш урынына бару өчен чыгымнар юл йөрү документларыннан башка, тиешле муниципаль орган сметасында каралганча, мөмкин булган чаралар чикләрендә түләнергә мөмкин (ләкин җәмәгать транспорты өчен түләүдән югары була алмый).

Командировкага җибәрелгән эшләүчегә чыгымнарны раслаучы документы (билеты) булган очракта, тимер юл станциясенә, пристаньга, аэропортка кадәр юл чыгымнары түләнә.

19. Эшләүчене ТР Минзәлә муниципаль районы Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы буенча, Россия Федерациясе территориясеннән читкә хезмәт командировкасына җибәрү командировка таныклыгын рәсмиләштермичә башкарыла, дәүләтара килешүләр төзелгән Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә кергән дәүләтләргә командировкага җибәргән очраклардан тыш (шулар нигезендә керү һәм чыгу

өчен документларда дәүләт чиген узу турында чик буе органнары тарафыннан билге куелмый).

20. Россия Федерациясе чикләреннән тыш хезмәт командировкасына чыгымнар нормасы һәм аларны кире кайтару тәртибе федераль дәүләт муниципаль хезмәткәрләре өчен билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә билгеләнә.

21. Эшләүче Россия Федерациясе территориясеннән чыкканда, аның Россия Федерациясе дәүләт чиген узган көне тәүлек акчалары (суточные) чит ил валютасында түләнгән көннәр исәбенә керә, ә Россия Федерациясе территориясенә кире кайтканда Россия Федерациясе чиген узган көн тәүлек акчалары сумнарда түләнгән көннәр исәбенә керә.

Россия Федерациясе территориясеннән чыкканда Россия Федерациясе дәүләт чикләрен узу һәм Россия Федерациясе территориясенә кире кайту даталары чик буе органнары эшләүченең паспортына куйган билгеләр, хезмәт паспорты һәм дипломат паспорты буенча билгеләнә.

Хезмәткәр ике яисә аннан да күбрәк дәүләт территориясенә хезмәт командировкасына җибәрелгәндә, илләр арасындагы чикләрне узган көн өчен тәүлек түләүләре эшләүче җибәрелгән илдә билгеләнгән нормалар буенча чит ил валютасында түләнә.

22. Эшләүчене керү һәм чыгу өчен документларда чик саклау органнары тарафыннан дәүләт чиген узу турында билгеләр куелмый торган хөкүмәтара килешенү төзелгән Берләшкән Дәүләтләр Бердәмлегенә керүче дәүләтләр территорияләренә хезмәт командировкаларына җибәргәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читкә чыкканда дәүләт чиген чыгу датасы куелмый, Россия Федерациясе территориясенә кергәндә Россия Федерациясе территориясе чикләрендә командировкаланган кебек рәсмиләштерелгән командировка таныклыгындагы тамга буенча билгеләнә.

Юлда тоткарланырга мәҗбүр булган очракта, бу чорга тәүлек акчалары тоткарлану фактын раслаучы документлар булганда, ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән түләнә.

23. Эшләүчене чит илләр территориясенә хезмәт командировкасына җибәргән очракта, юл чыгымнары Россия Федерациясе территориясе чикләрендә хезмәт командировкасына җибәргәндәге кебек тәртиптә кире кайтарыла.

24. Әгәр эшләүче ял һәм бәйрәм көннәрендә эшкә махсус командировкага җибәрелсә, бу көннәрдә эшләгән өчен компенсация Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнә.

ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы белән, эшләүче хезмәт командировкасына ял көне киткән очракта, хезмәт командировкасыннан кайткач, аңа билгеләнгән тәртиптә башка ял көне бирелә.

25. При направлении работника в служебную командировку ему выдается денежный аванс на оплату расходов по проезду, по найму жилого

помещения и дополнительных расходов, связанных с проживанием вне места постоянного жительства (суточные).

26. Эшләүче хезмәт командировкасыннан кайткач, өч хезмәт көне эчендә муниципаль органга билгеләнгән формада хезмәт командировкасы белән бәйле сарыф ителгән суммалар турында аванс отчеты тапшышырга һәм аңа командировка алдыннан командировка чыгымнарына бирелгән акчалата аванс буенча соңгы исәп-хисапны ясарга бурычлы.

Аванс отчетына тиешенчә рәсмиләштерелгән командировка таныклыгы, торак бинасы наемы турында, юл өчен чынлыкта тотылган чыгымнар турында документлар (транспортта пассажирларны мәҗбүри шәхси иминиятләүгә иминият взносын, юл йөрү документларын рәсмиләштерү буенча хезмәтләр өчен түләүне, поездларда урын-җир әйберләрен бирүне кертеп) һәм ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе рөхсәте белән башкарылган хезмәт командировкасына кагылышлы башка документлар да теркәлә.

27. Күләме билгеләнгән күләмнән артып киткән чыгымнар, шулай ук хезмәт командировкасы белән бәйле башка чыгымнар (алар эшләүче тарафыннан ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе рөхсәте белән башкарылган очракта) муниципаль органны тәртиптә тотуга сметада каралган акчалар хисабыннан муниципаль орган тарафыннан түләнә.

ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе рөхсәте белән башкарылган, хезмәт командировкасы белән бәйле башка чыгымнарны кайтару әлеге чыгымнарны раслаучы документлар булганда башкарыла.

28. Аерым очракларда, хезмәт командировкасының максатын һәм характерын исәпкә алып, ТР Минзәлә муниципаль район Башлыгы һәм ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе эшләүчеләргә чит ил дәүләтләрендә кыска вакытлы командировкаларда булган чорда беркетмә характерындагы чыгымнарга чит ил валютасында отчет таләп итми торган сумманы, башка төр түләүләрне, шулай ук делегация җитәкчеләренә югарыда күрсәтелгән түләүләрне башкаруга рөхсәт бирергә хокуклы.

29. Эшләүче һөнәри әзерлек, квалификация күтәрү, стажировка узу өчен командировкага җибәрелгән очракта, эшләүченең һөнәри әзерлеген, квалификациясен күтәрүен раслаучы документлар пакетын тапшырырга тиеш.